ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Куралово _______________

2 17.12.2015

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, 11 статьясы Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Куралово авыл җирлеге территориясендә түбәндәге сора буенча җирле референдум уздыруның уртак инициативасын чыгарырга:

«Сез 2015 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме:

- Рус Борнашы авылында һәм Куралово авылында урнашкан 2 км озынлыктагы зиратларга килү юллары төзү .

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы: Л.И.Коткова